**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

от «16» нче гыйнвар 2020 нчы ел № 3

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 2 декабрендәге 282 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Муниципаль идарә итү процессларының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм җайга салу карарларын әзерләү һәм кабул итү өлешендә муниципаль идарә итү процессларын камилләштерү һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан кабул ителә (чыгарыла) торган гамәлдәге норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын башлангыч һәм җентекле бәяләүне уздыру методикасын раслау турында» 2013 елның 2 августындагы 250 номерлы боерыгын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 2 декабрендәге 282 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 нче бүлекнең 3. 6 п. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«көндәшлек торышына акт проектының йогынтысын анализлау»

- 4 бүлекнең 4. 2 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмәдә профильле бүлекчә әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрнең проектта булуы, акт проектын кабул итүнең максатка ярашлылыгы турында нәтиҗә ясаган яисә аны эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр бирелгән очракта, проектны әзерләүче кисәтүләрне бетерергә тиеш.

Әгәр дә бәяләмәдә китерелгән профильле бүлек нәтиҗәләре нигезсез дип санаса, проектны әзерләүче, килештерелгән позициягә ирешү максатларында, профильле бүлекчә белән килештерү процедуралары үткәрә. Килештерелгән позициягә ирешмәгән очракта, проектчы беркетмә әзерли, аңа профильле бүлекчәнең җитәкчесе (яисә аның урынбасары) һәм проектчының җитәкчесе (яисә аның урынбасары) кул куя.

Алга таба акт проектын кабул итү процедурасын гамәлгә ашырганда, проект материалларына карата мәҗбүри тәртиптә килештерү процедуралары нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән беркетмә теркәлә.

Акт проектын әзерләүдән баш тарту яисә аны эшләп бетерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, эшләүче, җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмә һәм акт проекты буенча тәкъдимнәр җыентыгын алынганнан соң, 15 календарь көненнән дә соңга калмыйча, тиешле мәгълүматны рәсми сайтта урнаштыра.

Акт проектында әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләр ачыкламаган очракта, әзерләүче акт проектының йомгаклау редакциясен, шулай ук акт проекты буенча гавами консультацияләрдә катнашучылардан кергән

тәкъдимнәр җыентыгында булган тәкъдимнәрне исәпкә алу яисә кире кагу сәбәпләре турында мәгълүматны, җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмә алынган көннән алып 15 календарь көненнән дә соңга калмыйча һәм акт проекты буенча тәкъдимнәр җыентыгын әзерли.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, “Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Фәсахов Р.Р.**